■ Хәзрәт вәгазе

# ҮЛЕМ ХАКЫНДА БЕР МӘСЬӘЛӘ

Үлем - хәят вазифасыннан демобилизацияләнүдер, фани тормыштан бакый тормышка күчүдер, мәңгелек хәятка чакырудыр һәм мәңгелекнең дә башыдыр. Дөньяга килгәндә инсаннарга хәят бирү Аллаһының тәкъдире - язмышы сәбәпле, Аллаһының кодрәте белән була. Шуның кебек үк үлем дә Аллаһының теләге, Аллаһының кодрәте һәм хикмәте белән буладыр. Чөнки хәят мәртәбәләренең иң түбәнендә булган үсемлекләр доньясындагы үлемнәр аларның хәятларының яңадан башлануыдыр. Зира җимешләренең, орлык вә тышчаларының туфракка күмелеп үлүләре аркасында алар яңадан хәятланып, үсеп, җимеш бирү хәләнә керүләре белән терелерләр. Димәк, орлыкның үлүе сөмбелнең барлыкка килеүенең башыдыр.

Шулай булгач, инсаннарның үлемнәре дә яхшылыктыр һәм бер нигъмәттер, чөнки мәңгелек җәннәт тормышына бара торган ахирәт сәфәре үлем белән башлана.

Мәсәлән, без инсаннарның ашказаныбызда шундый сансыз җимешләр күмелеп үләрләр. Һәм хәлал суелып үлтерелгән хайваннарның итләре дә безнең ашказаныбызда күмелеп үләрләр. Әмма аларның ашказаныбызда аш булып үлүләре сәбәпле, безнең хәятыбыз дәвам итәр. Шулай булгач, "Алар үлем белән нәбати һәм хайвани хәят дәрәҗәсеннән инсани хәят мәртәбәсенә чыгып, тәраккый итәрләр. Димәк, аларның барысының да үлүләре рәхмәттер һәм нигъмәттер", - дип әйтергә ярый.

Иң түбән дәрәҗәдәге хәят - үсемлекләрнең һәм хайваннарның хәятыдыр. Әгәр аларның үлемнәре рәхмәт һәм нигъмәт булса, әлбәттә, иң югары хәят дәрәҗәсе булган инсаннарның үлемнәре дә рәхмәттер һәм нигъмәттер. Чөнки җир астына кергән мөьмин кешеләр дә мәңгелек хәят булган җәннәткә шунан юнәләләр.

Әмма үлемнең ничек нигъмәт булуын без түбәндәге дүрт әсас белән күрсәтәбез.

**БЕРЕНЧЕСЕ.** Хәятның авырлаша барган вазифасыннан һәм дөнья тормышының җаваплылыгыннан үлем белән азат ителеп, мондагы бер фани дус урынына җәннәттәге туксан тугыз бакый дусларга кавышуга сәбәп булуы аркасында, ул - зур бер нигъмәттер.

**ИКЕНЧЕСЕ.** Тар, сызланулы, дәгъвале һәм куркынычлы дөнья төрмәсеннән чыгарылып, киң, шатлыклы, газапсыз һәм мәңге бер хәят белән Мәхбүбү-Бакыйның (Аллаһның) рәхмәт даирәсенә ирешүдер.

**ӨЧЕНЧЕСЕ.** Картлык кебек тормыш шартларын авырлата торган бик күп начар сәбәпләр кешеләрне бу фани тормыштан биздерер, үлемне сөйдерер. Мәсәлән, сине сызландырып, күңелеңне борчыган бик авыр хәлдәге әбиләр һәм бабайлар синең әти-әниләрең белән бергә синең күз алдында һич үлмичә яшәсәләр иде, ул вакытта хәятның алар өчен газап, ә үлемнең нигъмәт булганын белер идең. Күзен үлгән нәзакәтле кечкенә бөҗәкләр әгәр хәятта калсалар иде, кыш көне алар бик газапланырлар иде. Хәлбүки, мәрхәмәт һәм шәфкать иясе булган Аллаһ, аларны көз көне үтереп, яз көне терелтә. Шуңа күрә ул үлем дә ул бөҗәкләргә рәхмәт була.

**ДҮРТЕНЧЕСЕ.** Авырып хаста булган кешеләргә йоклау бер рәхәтлек биреп, авырлыкларны онытырып һәм аларны сызланудан коткарып, тынычландырыр. Шуның кебек йокының зур туганы булган үлем дә кайбер бик авыр хәлдәге кешеләр өчен нигъмәттер һәм рәхмәттер.

Безнең мәсьәләбез булган үлемнең рәхмәт һәм нигъмәт булуы иман әһелләре өчендер. Ә кәфер әһелләре өчен үлем газап эчендә газаптыр. Һәм ул безнең мәсьәләбез тышындадыр.

■ Илхам

Рәсимә МУСТАФИНА,
Миәкә районы,
Кыргыз-Миәкә ауылы

### "БИСМИЛЛА"НЫ ӘЙТӘМ ҺӘР ЭШТӘ

Иртән торам "бисмилла"ны әйтеп,
Кич ятканда сүзем "Бисмилла".
"Бисмилла" дип эшемде башласам,
Гамәлләрем гелән уң була.

"Бисмилла"лы өйгә афәт керми,
"Бисмилла"лы эштә - бәрәкәт.
"Бисмилла"лар менән тиз уңала
Тән, җаныңда булса ярәхәт.

"Бисмилла"лы йортта үскән бала
Итәгәтле, изге санала.
Әдәпле һәм ипле булса алар
Тыныч яши ана доньяда.

### РӘХМӘТ, АЛЛАМ!

Гомер биргән өчен рәхмәт, Аллам,
Сөю биргән өчен өчләтә.
Сәламәтлек бирдең кызганмыйча,
Фани доньялыкта яшәргә.

Эшләгән эш, кылган гамәл
Булсын иде гелән изгелек.
Барысы өчен дә Сиңа мин
Бурычлымын иң элек.

Укыган бар догаларым
Сиңа барып җитсеннәр.
Юлларым да дөньялыктан
Оҗмахтарға илтсеннәр.

Кылган гонаһларым булса,
Кичерүләр көтәп каламын.
Тагын Сиңа сыйынамын,
Рәхмәт Сиңа, бер Аллам!

### БЕРДӘН-БЕРЕМ - СИН АЛЛАМ

Мәрхәмәтле, көч-көдрәтле,
Бердән-берем - син Аллам.
Нинди горур булсам да мин,
Синең каршында бер кол,
Баш эйми кала алмам.

Рәхмәтлемен, бирсәң дә син
Сынауларның авырын.
Сыналам да, сынмый калып,
Барыбер дә көтеп алам
Яңа көннең тыуарын.

Эй, Раббым, ташлама син
Мәрхәмәтеңнән берүк.
Парлы гомер насыйп әйлә,
Соңгы көннәремә кәдәр
Сәламәтлекләр биреп.

### ИСТИГФАР КЫЛ ТИЗЕРӘК

Гонаһларын күп кешеләр
Кылалар ләззәт өчен.
Әчелеге гонаһларның
Жиңәдер ләззәт көчен.

Бер минутлык ләззәтеңнең
Сиҙәсеңме үтеүен.
Җавап тоту өчен сиңа,
Вакыт килеп житеүен.

Вакытында аңлап барсын,
Килмәсәң син тәүбәгә.
Бәхетсезлек, хәерчелек,
Чирләр килә бәндәгә.

Кылган гонаһларын булса
Истигфар кыл тизерәк
Кайгы-хәсрәт, авырлыклар
Җиңеләйер әзерәк.

### Өфөлә намаҙ ваҡыты

**Зөлҡағиҙә 2010 миләди йыл**
**1431 һижри йыл.**

| Зөлҡағиҙә | Аҙна көндәре | Октябрь | Иртәнге намаҙ | Ҡояш сыға | Өйлә нам. | Икен. нам. | Аҡшам. | Йәстү намаҙы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Шәмбе | 9 | 7.03 | 8.33 | 14.30 | 18.03 | 19.33 | 21.03 |
| 2 | Йәкшәмбе | 10 | 7.05 | 8.35 | 14.30 | 18.01 | 19.31 | 21.01 |
| 3 | Дүшәмбе | 11 | 7.07 | 8.37 | 14.30 | 17.58 | 19.28 | 20.58 |
| 4 | Шишәмбе | 12 | 7.09 | 8.39 | 14.30 | 17.56 | 19.26 | 20.56 |
| 5 | Шаршамбы | 13 | 7.11 | 8.41 | 14.30 | 17.53 | 19.23 | 20.53 |
| 6 | Кесе йома | 14 | 7.13 | 8.43 | 14.30 | 17.51 | 19.21 | 20.51 |
| 7 | Йома | 15 | 7.15 | 8.45 | 14.30 | 17.49 | 19.19 | 20.49 |
| 8 | Шәмбе | 16 | 7.17 | 8.47 | 14.30 | 17.46 | 19.16 | 20.46 |
| 9 | Йәкшәмбе | 17 | 7.19 | 8.49 | 14.30 | 17.44 | 19.14 | 20.44 |
| 10 | Дүшәмбе | 18 | 7.21 | 8.51 | 14.30 | 17.42 | 19.12 | 20.42 |
| 11 | Шишәмбе | 19 | 7.23 | 8.53 | 14.30 | 17.39 | 19.09 | 20.39 |
| 12 | Шаршамбы | 20 | 7.25 | 8.55 | 14.30 | 17.37 | 19.07 | 20.37 |
| 13 | Кесе йома | 21 | 7.27 | 8.57 | 14.30 | 17.35 | 19.05 | 20.35 |
| 14 | Йома | 22 | 7.29 | 8.59 | 14.30 | 17.32 | 19.02 | 20.32 |
| 15 | Шәмбе | 23 | 7.31 | 9.01 | 14.30 | 17.30 | 19.00 | 20.30 |
| 16 | Йәкшәмбе | 24 | 7.33 | 9.03 | 14.30 | 17.28 | 18.58 | 20.28 |
| 17 | Дүшәмбе | 25 | 7.35 | 9.05 | 14.30 | 17.25 | 18.55 | 20.25 |
| 18 | Шишәмбе | 26 | 7.37 | 9.07 | 14.30 | 17.23 | 18.53 | 20.23 |
| 19 | Шаршамбы | 27 | 7.39 | 9.09 | 14.30 | 17.21 | 18.51 | 20.21 |
| 20 | Кесе йома | 28 | 7.41 | 9.11 | 14.30 | 17.19 | 18.49 | 20.19 |
| 21 | Йома | 29 | 7.43 | 9.13 | 14.30 | 17.17 | 18.47 | 20.17 |
| 22 | Шәмбе | 30 | 7.45 | 9.15 | 14.30 | 17.15 | 18.45 | 20.15 |
| | | | ҠЫШҠЫ ВАҠЫТ | | | | | |
| 23 | Йәкшәмбе | 31 | 6.47 | 8.17 | 13.30 | 16.13 | 17.43 | 19.13 |
| 24 | Дүшәмбе | 1 | 6.49 | 8.19 | 13.30 | 16.10 | 17.40 | 19.10 |
| 25 | Шишәмбе | 2 | 6.51 | 8.21 | 13.30 | 16.08 | 17.38 | 19.08 |
| 26 | Шаршамбы | 3 | 6.53 | 8.23 | 13.30 | 16.06 | 17.36 | 19.06 |
| 27 | Кесе йома | 4 | 6.55 | 8.25 | 13.30 | 16.04 | 17.34 | 19.04 |
| 28 | Йома | 5 | 6.57 | 8.27 | 13.30 | 16.02 | 17.32 | 19.02 |
| 29 | Шәмбе | 6 | 6.59 | 8.29 | 13.30 | 16.00 | 17.30 | 19.00 |

## КРОССВОРД



1. Дүрт бөек фәрештәнең берсе, пәйгамбәрләр һәм Аллаһ арасында илче булган.
2. Бу изге кичә 26-нчы рәҗәбнең төненә тура килә. Бу төнне Мөхәммәд (с.г.в.) күккә ашып, Аллаһ белән сөйләшә.
3. Мөхәммәд пәйгамбәрзән (с.г.в.) соң илдә патшалык иткәннәрнең титулы.
4. Иң беренче мөэмин, кара кол булган.
5. Аллаһ Тәгаләнең җирдәге илчеләре.
6. Дүртенче хәлифә, ул идарә иткәндә мөселманнар шигайларга һәм сөнниләргә бүленә.
7. Гарәпчәдән угълы дип тәрҗемә ителә. Гарәп исемнәренең бур өлеше.
8. Ир-ат - мөселман, хатын кыз - ?

**Кроссворд җаваплары ("Рисәләт", №9)**

**Сулдан уңга:** 1. Мостафа. 2. Какы. 3. Һәлал. 4. Ара. 5. Җәйге. 6. Им. 7. Рәил. 8. Риза.

**Өстән аска:** 1. Мөһажир. 2. Әрәмә. 3. Гали. 4. Аккаен. 5. Фа. 6. Азан.

## "Бала гына бит ул" дип уйламагыз



Беркөнне Хәзрәте Гомарнең хатыны улы Габдуллаһны:

- Улым, кил әле монда. Кара, сиңа нәрсә бирәм, - дип, үзенә чакыра. Бу вакытта рәсүлебез аларның өендә кунакта була.

Ул Габдуллаһның әнисеннән:

- Улыңа нәрсә бирмәкче идең, - дип сорый.

Әнисе:

- Хөрмә бирмәкче идем, йә Рәсүлуллаһ! - ди.

Моңа каршы Рәсүлебез:

- Бик яхшы. Әмма, бирәм дип вәгъдә итеп, берни бирмәгән булсаң, сиңа ялган сөйләгән кебек гөнаһ языла иде, - дип кисәтә.